# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлегенең Әлмәт авылы торак пунктында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

**№1** **22.11.2021**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары нигезендә 2021 елның 22 ноябрендә «I нче группа инвалидлар; ялгыз өлкән кешеләр; вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар; көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан кала, Әлмәт авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2022 елда үзара салымны 300 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

1) Әлмәт авылында шлагбаумнарны реконструкцияләү ( төзелеш, коелган материаллар сатып алу);
2) Әлмәт авылында буяулар, янгынга каршы инвентарь, триммерларга запас частьләр сатып алу;
3) Әлмәт авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту);
4) Әлмәт авылында МТЗ 82.1 тракторына хезмәт күрсәтү (ягулык-майлау материаллары, өстәмә җиһазлар, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү);
5) Әлмәт авылында Ленин урамы, Тукай урамы, Яшьләр урамы, Л. Рәхмәтуллин урамы буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (материаллар сатып алу һәм ташу);
6) Әлмәт авылында массакүләм чаралар (өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, 9 Май, «Сабантуй», юбилярларны һәм алдынгыларны хөрмәтләү, спорт чаралары) үткәрү өчен бүләкләр алу;

ӘЙЕ ЮК?».

мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 318 катнашучы кертелгән, җыенда катнашучылар саны 194 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 194 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге составына керүче Әлмәт авылында узган халык җыенын-уздырылган, нәтиҗәләрен- дөрес дип танырга
2. Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге составына керүче Әлмәт авылында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга: «I нче группа инвалидлар; ялгыз өлкән кешеләр; вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар; көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан кала, Әлмәт авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2022 елда үзара салымны 300 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:
1) Әлмәт авылында шлагбаумнарны реконструкцияләү ( төзелеш, коелган материаллар сатып алу);
2) Әлмәт авылында буяулар, янгынга каршы инвентарь, триммерларга запас частьләр сатып алу;
3) Әлмәт авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту);
4) Әлмәт авылында МТЗ 82.1 тракторына хезмәт күрсәтү (ягулык-майлау материаллары, өстәмә җиһазлар, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү);
5) Әлмәт авылында Ленин урамы, Тукай урамы, Яшьләр урамы, Л. Рәхмәтуллин урамы буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (материаллар сатып алу һәм ташу);
6) Әлмәт авылында массакүләм чаралар (өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, 9 Май, «Сабантуй», юбилярларны һәм алдынгыларны хөрмәтләү, спорт чаралары) үткәрү өчен бүләкләр алу;

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Сарман муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм Әлмәт авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
4. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әлмәт авыл җирлеге башлыгы: Д. Ә. Газизов